ГЛАВА ЧЕМОДУРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.1а, с.
Чемодурово, 423307

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧЕМОДУРОВО
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
БАШЛЫГЫ
Нагорная ур., 1а нче йорт,
Чемодурово авылы, 423307

Тел./факс(885592)3-31-61; E-mail:Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От 05.11.2019 №2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Чемодур торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Чемодурово торак пунктында, Чемодур авылында теркәлгән һәм Үзәк урамы буенча 1-75, Нагорный урамы буенча 1-9 нчы йортларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Чемодурово торак пунктында, Чемодурово авылында теркәлгән һәм Яшьләр урамы буенча 1-23 , Лесная урамы буенча 1-6 нчы йортларда

үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә .

Билгеләү:

– Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Чемодурово авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2019 елның 15 ноябре, 13.00 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр;

- гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2019 елның 15 ноябре, 13.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны-Чемодурово авылы, Нагорная урамы, 3А йорт, Чемодур авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2019 елның 5 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча: Чемодурово авылы, Үзәк урамы, 4а йорт , Молодежная урамы, 20А йорт. -Яңа материал-ны үзләштерү Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү уку эшчәнлеген оештыра белү.;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Чемодур авылы халкына, массакүләм мәгълүмат чараларына һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4 . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Чемодур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш,300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»;
- Чемодур авылында зират коймасын алыштыру;
- Чемодур авылында үлән чаптыру, чүп-чар җыю хезмәтләре.
- Чемодур авылында юлларны кардан чистарту;
- Чемодур авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар халыкка урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең, түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендлары;:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Чемодур авылы, Үзәк ур., 4а;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Чемодур авылы, Яшьләр ур., 20а;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис: Н.Б.Котельникова